Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР №XLII-3**

Балык Бистәсе штп. 2023 елның 26 сентябре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 21 ноябрендәге XXIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 маендагы 126-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, муниципаль норматив хокукый актны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы «Балык Бистәсе муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советының 2017 елның 21 ноябрендәге XXIII-3 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар йөртүне оештыру Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1) 6 бүлекнең 29 пунктында «муниципаль контракт белән» сүзләреннән соң «яисә концессия килешүе яки муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү нигезендә» сүзләрен өстәргә, «әлеге контракт» сүзләрен «контракт яки концессия килешүе, муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү мәгълүматлары» сүзләренә алыштырырга;

1.2) 4 нче бүлекнең 17 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«17. Муниципаль заказчы, концедент, гавами партнер муниципаль контракт яки муниципаль-хосусый партнерлык турында килешү гамәлдә булган вакытка, концессия килешүе яки муниципаль-хосусый партнерлык муниципаль контракт төзелгән затка даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрына кертелгән даими ташу маршруты картасын, Федераль законның 26 маддәсендәге 1 өлешенең 13 пунктында күрсәтелгән мәгълүматларны бирә.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны транспорт, төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район
Башлыгы Р.Р. Ислямов